Татарстан Республикасы
Казан шәһәре Авиатөзелеш районы “134 нче татар-рус урта гомуми белем бирү мәктәбе”
гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесе

| **Каралды:** | **Килешенде :** | **Расланды:** |
| --- | --- | --- |
| МБ утырышы беркетмәсе №1<br>МБ җитәкчесе<br>__________ А.Җ. Зәйнуллина<br>Дата 25.08.2015 | Директор урынбасары<br>_____ ____ Н.Б . Мусина<br>Дата .08.2015 | Мәктәп директоры<br>_________ А.С.Петров<br>Педагогик совет утырышы беркетмәсе №1<br>Дата .08.2015 |

***Эш программасы***

Фән- татар теле.
6 нчы “А” сыйныфы, татар төркеме.
Ф.И.О.- Зәйнуллина Альмира Җиһангәрәй кызы, югары квалификацион категорияле
Гамәлдә куллану вакыты-2015/16 нчы уку елы

Казан, 2015-2016 нчы уку елы.

## Аңлатма язуы

**Эш программасы түбәндәге дәүләт документларына нигезләнеп төзелде**:

1. Россия  Федерациясе конституциясе 12.12.1993 (РФ Конституциясенә 30.12.2008 елда №6-ФКЗ, 30.12.2008 елда №7-ФКЗ,21.07.2014 елда №11-ФКЗ белән кергән үзгәрешләр исәпкә алынды.
2. Татарстан Республикасы Конституциясе 6.11.1992(үзгәрешләр һәм әстәмәләр белән)
3. .29.12 2012 нче елда кабул ителгән 273 нче номерлы "Россия Федерациясендә Мәгариф турында" Федераль кануны.
4. 22.07. 2013 нче елда кабул ителгән 68 нче номерлы "Мәгариф турында" Татарстан Республикасы кануны.
5.8.07.1992 нче елда кабул ителгән 1560 – XXII номерлы  "Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында" ТР кануны.
6.. 17.12.2010 елда кабул ителгән 1897 номерлы төп гомуми белем бирүнең(ООО) Федераль дәүләт белем стандарты..
7.ТР  Мәгариф министрлыгының 7699/12 номерлы боерыгы, 23.06.2012 ел "Об учебных планах для 1-11 классов школ РТ, реализующих основные образовательные программы начального общего образования и основного общего образования в соответствии с ФГОС общего образования".
8. ТР  Мәгариф министрлыгының 9807/12 номерлы хаты, 13.08.2012 ел "О преподавании татарского государственного языка в общеобразовательных учреждениях РТ" һәм  №9777/12  номерлы хаты, 13.08.2012 ел "Об изучении татарского языка и литературы в образовательных учреждениях".
9."Рус телендә урта(тулы) гомуми белем бирү мәктәпләре өчен татар теле һәм әдәбиятыннан үрнәк программалар " 1-11  нче сыйныфлар.Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Казан,  Татарстан китап нәшрияты, 2011 нче ел. Ф.Ф.Харисов, Ч.М.Харисова, В,А,Гарипова авторлыгында. (программа федераль дәүләт белем стандартларына (ФГОС) нигезләнеп төзелгән).
10. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм Фән министрлыгының 2015/2016 нчы уку елында татар телен укыту үзенчәлекләре.Методик тәкъдимнәр.Казан.2014ел
11. СанПиН 2.4.2.2821-10 "Гомуми белем бирү учрежденияләрендә укыту өчен шартлар һәм укытуны оештыруга санитар-эпидемиологик таләпләр" (РФның баш дәүләт санитар табибының 189 нчы номерлы карары. 29.12.2010 ел)
12. Казан шәһәре Авиатөзелеш районы "134 нче татар-рус урта гомуми белем бирү мәктәбе" гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесенең 2015/2016 нчы  уку елына уку-укыту планы**.**

**Дәреслек:**Н.В.Максимов, М.З.Хәмидуллина. "Татар теле , 6нчы сыйныф",Рус телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы , Казан, Татарстан китап  нәшрияты, 2015 нче ел.

**Эш программасының структурасы**

Татар теленең эш программасы өч өлештән тора: аңлатма язуыннан, төп бүлекләрне, белем һәм күнекмәләрне үз эченә алган программаның эчтәлегеннән, укучыларның әзерлек дәрәҗәсенә таләпләреннән.

**Укыту фәненең уку планында тоткан урыны**

”Рус телендә урта(тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә татар телен һәм әдәбиятын укыту программасы” буенча 6 нчы сыйныфта татар теле өчен елга 105 сәгать каралган. 6 нчы мәктәпнең базис укыту планы буенча 6 нчы сыйныфта уку елы 35 атна тәшкил итә: атнага 3 сәгать татар теле. Барлыгы елга 105 сәгать.

Эш программасы 1 елга төзелде.

**Эш программасының эчтәлеге**

Рус мәктәбендә укучы татар балаларына ана теленнән системалы фәнни, ныклы белем бирелә, тел һәм сөйләм күнекмәләре булдырыла, ягъни танып белү, гамәли юнәлештәге эш тормышка ашырыла.

**Рус мәктәбендә татар телен ана теле буларак укытуның максатлары:** Укучыларда лингвистик (тел), аралашу (коммуникатив), этнокультура өлкәсенә караган (культурологик) компетенцияләр булдыру.

**Лингвистик компетенция** фонемалар, морфемалар, сүз ясалышы, сүзтезмәләр, җөмләләр, җөмлә кисәкләре, лексик һәм грамматик берәмлекләр, лингвистик анализ һ.б. ны үз эченә ала.

**Аралашу компетенциясе** ул – башкалар әйткәнне аңлау һәм үз фикереңне белдерү өчен тупланган белем, осталык, күнекмәләр җыелмасы; хәзерге татар әдәби теле нормаларына ия булу, сүз байлыгын, сөйләмнең грамматик ягын дөрес итеп үзләштерү; телдән һәм язма формада бәйләнешле сөйләм күнекмәләрен булдыру һ.б.

**Этнокультура өлкәсенә караган компетенция**, ягъни телне милли-мәдәни яссылыкта үзләштерү ул – укучыларны сөйләргә өйрәткәндә, рухи, эстетик тәрбия һәм белем бирү чарасы буларак, милли үзенчәлекләрне чагылдырган текстлар белән эшләү, тормыш-көнкүреш, гореф-гадәт үзенчәлекләрен, сынлы сәнгать әсәрләрен, халык авыз иҗаты үрнәкләрен белү, татар сөйләм этикетына ия булу.

**Рус мәктәбендә татар телен ана теле буларак укытуның төп бурычлары:**

1. Татар телен өйрәнүгә карата башлангыч сыйныфларда нигез салынган кызыксынуын көчәйтү, үз милләтеңә, хөрмәт белән карау, шулай ук татар теле аша башка милләт вәкилләренә, аларның рухи мирасына мәхәббәт хисе тәрбияләү.
2. Татар теленең барлык тармаклары буенча эзлекле рәвештә фәнни белем бирү.
3. Сөйләм эшчәнлеген белүгә ныклы күнекмәләр булдыру, туган телдә матур һәм дөрес аралашырга өйрәтү.
4. Телдән һәм язма сөйләм осталыгын камилләштерү. Көндәлек тормышта татар теле мөмкинлекләреннән тулысынча файдалана белергә өйрәтү.
5. Туган тел аша өзлексез белем һәм тәҗрибә туплау.
6. Татар телен башка фәннәрдә белем алу чарасы буларак кулланырга өйрәтү күнекмәләрен булдыру.

7. Укучыларны даими рәвештә татар милли мәдәнияте мирасына тарту.
8. Татар теле дәреслегендә, белем бирү белән бергә, тәрбияви бурычны да онытмау. Изложение, сочинениеләр дә тәрбияви бурычны күз уңында тотып яздырылырга тиеш.
9. Программа укучыларның логик фикерләү дәрәҗәсен үстерү бурычын да куя. Балалар, ана телендә аралашканда фикерләрен ачык, аңлаешлы, эзлекле, стилистик яктан дөрес, төгәл итеп адресатка җиткерә белергә тиеш. Бу бер үк вакытта сөйләм теленә дә, язма телгә дә карый, ягъни укучыларда ана телендә дөрес, матур итеп сөйләү һәм язу күнекмәләре тәрбияләү максаты куела.
10. Дәреслек, өстәмә һәм белешмә әдәбият белән эш итү, уку, язу күнекмәләрен камилләштерү программаның җитди таләпләреннән санала.
Рус мәктәпләрендә укучы татар балаларының күбрәк рус телендә аралашуларын һәм фәннәрнең рус телендә үзләштерелүен истә тотып, темаларны үткәндә, аның рус телендәге үзенчәлеген охшаш яки аермалы якларын) кыскача билгеләп бару зарур.
Программа тел белеме тармаклары арасыннан системалылык һәм эзлеклелек, фәннилек, аңлаешлылык, һ.б. таләпләрне истә тотып төзелде.
6 нчы сыйныфта 5 нче сыйныфта үткәннәр искә төшерелә. Исем темасын дәвам итеп, 6 нчы сыйныфта катлаулырак темалар үтелә, исемнәрнең ясалыш ысуллары өйрәнелә. Исемнәрне морфологик яктан тикшереп, алар буенча йомгак ясала.
Сыйфатларны өйрәнгәндә, аларның төркемчәләре дә үтелә (моңарчы ул кертелмәгән иде), асыл һәм нисби сыйфатларны бер-берсеннән аера белү күнекмәләре бирелә. Дәресләрдә сыйфатларның исемләшүенә игътибар артырга тиеш, чөнки, рус теленнән аермалы буларак, бу – телебездә еш очрый торган күренеш. Сыйфатларның төрле ысуллар белән ясалышы, аларны морфологик яктан тикшерү теманы йомгаклый.
Саннарның саналмыш белән кулланылу үзенчәлеге, татар телендә аларның исемләшүе, сан төркемчәләре, аларның ясалышы һәм дөрес язылышы өйрәнелгәч, морфологиик анализ ясала.
Рәвеш турында мәгълүмат беренче тапкыр 6 нчы сыйныфта бирелә. Аларның төркемчәләрен, ясалыш үзенчәлекләрен өйрәнгәннән соң, морфологик анализ ясап, бу сүз төркеме хакында нәтиҗә чыгарыла.
Алмашлык – 6 нчы сыйныфта үтелә торган ахыргы сүз төркеме. Башлангыч сыйныфларда зат һәм сорау алмашлыклары инде өйрәнелгәнгә күрә, калган биш төркемчәгә вакыт та күбрәк бирелә. Аларның сөйләмдәге әһәмияте ассызыклана, морфологик анализ ясау күнекмәләре тирәнәйтелә.
Рус мәктәбендә укучы татар балаларын бәйләнешле сөйләмгә өйрәтү даими алып барыла торган мөһим бурычлардан санала. Бәйләнешле сөйләм үстерү дәресләре укучыларны дөрес, матур, үтемле һәм аңлаешлы итеп сөйләргә, язарга, язганны укып  аңлата белергә, тегे яки бу мәсьәләгә карата үз фикереңне белдерергә, иҗади эшләр белән шөгыльләнергә өйрәтү максатларын куя.
Сөйләм культурасын үстерү укучыларның яшь үзенчәлекләрен һәм белем дәрәҗәләрен исәпкә алып, шулай ук үтелгән темаларга таянып алып барыла. Һәм сыйныф өчен программада каралган темаларны үткәннән соң, шуларга туры китереп, төрле биремнәр һәм иҗади эшләр эшләтү укучыларның материалны тирәнрәк үзләштерүенә, теорияне практикада куллана алуларына ирешүгә ярдәм итә, шул ук вакытта логик фикер йөртә белү һәм сөйләм телен үстерүгә дә булыша. Татар теле дәресләрендә сөйләм телен үстерү, гадәттә, түбәндәге өч юнәлештә алып барыла.
*Беренче юнәлеш* телебезнең әдәби нормаларын үзләштерүдән гыйбарәт. Бу – сүзләр ясалышында ялгышлар җибәрмәү, җөмләләр төзегәндә, стилистик кагыйдәләргә буйсыну, сүрәтләү чараларыннан киң файдалану һәм фразеологик әйтелмәләрне урынлы куллана белү.
Рус мәктәпләрендә укучы татар балалары күп вакыт русча фикер йөртә, сөйләмдә еш кына рус сүзләрен катнаштыра, җөмләдә сүз тәртибен һәм бәйләнешен бутый, сүз басымын дөрес куймый һәм башка шундый типтагы хаталар җибәрә.

Укучылар сөйләмендәге теге яки бу типик хаталарны бетерү өчен, системалы эш алып барылырга тиеш. Мәсәлән, татар теленә хас булган үзенчәлекле авазларның дөрес әйтелешен өйрәтүне фонетика бүлегенә караган темаларны үткәндә, җөмлә кисәкләренең җөмләдәге урынын синтаксисны өйрәнгәндә генә үзләштерергә кирәк дип карарга ярамый. Бу – һәр көн, һәр дәрестә һәм дәрестән тыш та алып барылырга тиешле эш. Шулай ук ике телне (татар һәм рус телләрен) өйрәнүне чагыштырып алып бару да уңай нәтиҗәләр бирә.

Укучыларның сөйләм телен үстерүдәге *икенче юнәлеш* – аларның сүз байлыгын арттыруга, һәр сүзне урынын белеп куллануга ирешүне максат итеп куя. Укучыларның сүз байлыгын даими арттыру, татар телендәге алынма сүзләрне, мәгънәләрен аңлап, урынлы куллану, төрле сүзлекләр белән эш итәргә өйрәтү – бу юнәлештәге төп бурычлар менә шулар.

Рус мәктәбендә укыганлыктан, рус теленең йогынтысы көчле булу һәм үзара татарча сирәк аралашу укучыларның сөйләмен үстерүдә кайбер кыенлыклар да тудыра. Шуңа күрә аңлашу, аралашуда ярдәм итә һәм көндәлек тормышта киң кулланыла торган сүзләрне иң беренче чиратта өйрәтү бик мөһим. Һәр сыйныф өчен *өченче юнәлеше* тәкъдим ителә торган лексик-фразеологик минимумны өйрәнүдә укытучыларга шулай ук иҗади эшләү мөмкинлеге дә тудырыла. Укучыларының яшь үзенчәлекләрен, укуга сәләтен һәм белем дәрәҗәләрен исәпкә алып, бу минимум составына кергән сүзләрне укытучы үзе сайлый һәм үзгәртә ала. Сөйләм үстерүнең– укучыларның әйтергә теләгән фикерен сөйләмә һәм язма формада, ягъни телдән һәм язма рәвештә, аңлаешлы һәм бәйләнешле итеп җиткерә белүләренә ирешү. Бу исә чыгышлар ясаганда, сочинение һәм изложениеләр язганда, әдәби әсәрләргә анализ биргәндә, дәрестә һәм сыйныфтан тыш чаралар вакытында тормышка ашырыла. Күрсәтелгән юнәлеш буенча эшләгәндә, укучылар бирелгән текстның төп темасын ачыкларга, аны анализларга, план төзергә, бүлекләргә аерып, чикләрен күрсәтергә, төп фикерне билгеләргә, сурәтләү чараларын таба белергә тиешләр.

Сөйләм телен үстерергә әдәбият дәресләрендә дә даими рәвештә игътибар итәргә кирәк. Бу уңайдан укытучы милли-төбәк компонентының эчтәлеген тәшкил иткән татар мәдәниятен, тарихын, гореф-гадәтләрен, йолаларын чагылдырган, аерым төбәктә яшәүче күренекле шәхесләр яки вакыйгаларны сурәтләгән әдәби әсәрләрдән, текстлардан киң файдаланыра тиеш.

Яңа сүзләрне өйрәтү һәм ятлату белән генә чикләнмәскә, аларны язма эшләр вакытында, хикәя, изложение һәм сочинениеләр язганда файдалана белергә, диалог төзегәндә дә, сөйләмдә дә кулланырга өйрәтергә кирәк.

**Яңа уку елы башына укучыларның белем, осталык һәм күнекмәләренә кыскача характеристика.**

**Фонетика:**

1. Сузык һәм тартык авазларның классификациясен, алардагы үзгәрешләрне белү. Сингармонизм законын, рәт һәм ирен гармониясе үзенчәлекләрен сөйләмдә дөрес куллану.
2. Татар телендә иҗек калыплары, сүзләрне дөрес басым белән әйтү. Тиешле интонация белән сөйләү.
3. Аваз һәм хәрефләрне аера белү. Алфавитны истә калдыру.
4. Сүзләргә фонетик анализ ясау.
5. Орфоэпик сүзлекләрдән файдалану.

**Лексика һәм фразеология:**

1. Татар теленең сүзлек составын килеп чыгуы, кулланылу өлкәсе һәм кулланылу дәрәҗәсе буенча бәяли белү.
2. Сүзләрне һәм фразеологизмнарны урынлы куллану, аларның мәгънәләренә аңлатма бирә белү. Синоним, омоним, антоним сүзләрне дөрес куллану.

3. Төрле типтагы сүзлекләрдән файдалана белү.
Сүз төзелеше һәм сүз ясалышы:
1.Сүзләрнең мәгънәле кисәкләренә аңлатма бирә белү. Тамырдаш сүзләр табу. Сүзләрне төзелеше һәм ясалышы буенча тикшерү.
2. Татар телендә сүзләрнең ясалыш ысулларын белү.

**Морфология:**
1. Исемнәрне килеш һәм тартым белән төрләндерү. Исемнәргә морфологик анализ ясау күнекмәләре булдыру(уртаклык яки ялгызлык булуы, берлектә яки күплектә килүе, килеше, тартым белән төрләнүе-төрләнмәве, нинди җөмлә кисәге булып килүен күрсәтү).
2. Сыйфатларның төрле дәрәҗә формаларын ясау(гади, чагыштыру, артыклык һәм кимлек). Дәреслектәге һәм укытучы тарафыннан бирелгән сыйфатларның төрле дәрәҗә формаларын ясап, алар белән җөмләләр төзү.
3. Микъдар һәм тәртип саннарын билгеләү, аларны сөйләмдә дөрес куллану.
4.Тартым, зат алмашлыкларын телдән һәм язма сөйләмдә дөрес куллану.
5. Боерык фигыльләрне зат-сан белән төрләндерү, хикәя фигыльләрнең барлык заманнарын зат-сан белән төрләндереп, аларны сөйләмдә, изложение һәм сочинение язганда дөрес куллану.
**Синтаксис:**
1. Җөмләнең баш кисәкләрен табып , аларның нинди сүз төркеме белән белдерелүен әйтү. Аергычны табып, аның сыйфат һәм сан белән белдерелүен күрсәтү.
2. Җыйнак һәм җәенке җөмләләрне телдән һәм язма сөйләмдә дөрес куллану.
3. Тиңдәш кисәкләрне билгеләү, алар янында тыныш билгеләрен дөрес куллану.
4. Эндәш сүзләрне иядән аеру, алар янында тыныш билгеләрен дөрес кую.
5. Җөмләгә синтаксик анализ ясау күнекмәләре булдыру(ия, хәбәр, аергыч, тиңдәш кисәкләрне күрсәтә белү).
**Сөйләм эшчәнлеге:**
Бирелгән терәк сүзләрне кулланып, кечкенә хикәяләр төзү. Өйрәнелгән сүз төркемнәрен файдаланып, яраткан ел фасылы турында кечкенә хикәя язу. Хикәя һәм сорау җөмләләрне файдаланып, укыган китап яки караган спектакль буенча диалог төзү. Бирелгән текстка план төзү. Бирелгән репликалардан логик бәйләнешле диалог төзеп язу. Бирелгән фразеологик әйтелмәләрне бер телдән икенче телгә тәрҗемә итү. Текстлар тәрҗемә итү. Изложение, сочинение язарга өйрәнү. Төрле характердагы диктантлар язу.

**6нчы сыйныф укучыларының белем, осталык һәм күнекмәләренә төп таләпләр.**

6 нчы сыйныфта бирелә торган осталык һәм күнекмәләр (1-5 сыйныфларда алган белемнәргә өстәп күрсәтелә **).** Алдагы сыйныфларда алган белем һәм күнекмәләрне ныгыту.
**Морфология:**
1. Сүз төркемнәрен лексик-грамматик мәгънәсе, морфологик һәм өлешчә синтаксик билгеләре буенча аера һәм аларны таный белү. Исем, сыйфат, сан, алмашлык һәм рәвеш сүз төркемнәренә морфологик анализ ясый белү.

Өйрәнелгән сүз төркемнәре белән җөмләләр һәм текстлар төзү. Сүз төркемнәренең төрле ысуллар белән ясалышын белү.
**Сөйләм эшчәнлеге:**
1. Юл йөрү кагыйдәләрен белүне күрсәткән, 7-8 репликадан торган диалог төзү.
2. Эш кәгазьләреннән эти - әниеңә яки туганнарыңа рәхмәт хаты, табигатьне саклау турында газетага мәкалә яза белү.
Укучыларның тормыш тәҗрибәсеннән чыгып, өйрәнелгән сүз төркемнәрен файдаланып, кечкенә хикәяләр төзү.
Төрле характердагы сочинениеләр язу.
Сүз төркемнәрен өйрәнгәч, алган белемнәренә таянып, грамматик биремле диктантлар язу.
Төрле сүз төркемнәре кергән җөмләләрне татарчадан русчага һәм русчадан татарчага тәрҗемә итә белү.Сүзләрне куллану.
Уңай кешелек сыйфатлары тәрбияләүмаксатыннан чыгып сайланган текстлар буенча изложениеләр язу.

**6 нче сыйныфны тәмамлаган татар балалары (рус мәктәбендәге) үзләштерергә тиешле белем-күнекмәләр**
- телдән һәм язма сөйләм, диалог һәм монолог, текст төшенчәләрен аңлау һәм гамәлдә дөрес куллану;
- тыңлап аңлау һәм уку буенча телдән һәм язма рәвештә хабәр ителгән мәгълүматны аңлау;
- сөйләү һәм язуда татар әдәби теленең төп нормаларын саклау;
- татар теленең фонетик, лексик системаларын һәм грамматик төзелешен үзләштерү;
- сүзләргә фонетик анализ ясау;
- сүзләрне төзелеше һәм ясалышы буенча тикшерә белү;
- сүз төркемнәренә морфологик анализ ясау;
- сорауларга тулы һәм дөрес итеп җавап бирү;
- текстның планын төзү, тәкъдим ителгән текстларны рус теленнән татар теленә һәм татар теленнән рус теленә тәрҗемә итү.

**Укучыларның әзерлек дәрәҗәсенә таләпләр:**
- ана теленең төп берәмлекләрен һәм аларның билгеләрен белү;
- телдән һәм язма сөйләм, диалог, монолог, аралашу ситуацияләрендә тел стильләре, текст төшенчәләрен аңлау һәм гамәлдә дөрес куллану;
- тыңлап аңлау һәм уку буенча телдән һәм язма рәвештә (радио, телеведениедән һ.б.) хәбәр ителгән мәгълүматны аңлау;
- сөйләү һәм язуда татар әдәби теленең төп нормаларын (орфоэпик, лексик, грамматик, орфографик һәм пунктацион)саклау һәм сөйләм әхлагы нормаларын үтәү;
- татар теленең фонетик, лексик системаларын һәм грамматик төзелешен өлешчә үзләштерү;
- сүзләрне төзелеше һәм ясалышы буенча тикшерә белү;
- ана теленең грамматик категорияләрен белү;
- грамматик үзенчәлекләренә карап, сүз төркемнәрен аера белү;
- сүз төркемнәренә морфологик анализ ясау;
- сүз, сүзтезмә, җөмләләрдәге хаталарны төзәтү;

- төрле сүзлекләрдән һәм белешмә характерындагы китаплардан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан урынлы файдалану;
- текстның эчтәлеген телдән яки язмача төгәл итеп, сайлап яки кыскача, гади җөмләләр кулланып сөйли белү;
- бирелгән темага, куелган максатка ярашлы рәвештә, төрле ситуацияләрдән чыгып, сурәтләү яки хикәяләү характерындагы текстларны телдән яки язмача әзерләү;
- сорауларга тулы һәм дөрес итеп җавап бирү;
- төрмыш-көнкүреш, уку, иҗтимагый, мәдәни темаларга әңгәмә кору, үз фикереңне яклап, әңгәмә-бәхәс формасында сөйләшү күнекмәләренә ия булу
- текстның планын төзү яки аның эчтәлеген конспект формасында язу;
- тәкъдим ителгән текстларны рус теленнән татар теленә һәм татар теленнән рус теленә тәрҗемә итү;
- ана теленең башка фәннәрне өйрәнү һәм белем алу чарасы икәнен аңлау;
- татар теле дәресләрендә алган белем һәм күнекмәләрне ана теленең кеше һәм җәмгыять тормышында алып торган урынын аңлап куллана һәм бәяли белергә өйрәнү, татар теленең Татарстан Республикасында дәүләт теле буларак өйрәнелүен, аның иҗтимагый әһәмиятенең артуын аңлау.

**VI сыйныфта татар теленнән үзләштерелергә**
**һәм камилләштерелергә тиешле универсаль белем һәм күнекмәләр.**

| Уку эшчәнлеген оештыра белү юнәлешендә | Китап, өстәмә мәгълүмат белән эш итә белү | Фикерләү белән бәйле күнекмәләр | Телдән һәм язма сөйләм үстерү һәм аралаша белү юнәлеше |
|---|---|---|---|
| 1. Уку мәсьәләләрен мөстәкыйль билгеләү.<br>2. Уку операцияләрен планлаштыру.<br>3. Белем алуның рациональ ысулларын сайлау.<br>4. Үз-үзеңә контроль ясауның төрле формаларын үзләштерү.<br>5. Мөстәкыйль белем алу буенча эш башлау. | 1. Дәреслек белән эш итә белү.<br>2. Төрле чыганаклар белән мөстәкыйль эш итә белү.<br>3. Төрле текстлар белән эш иткәндә сәнгатьлелекне саклый белү.<br><br>4. Сүзлекләрдән файдалана белү, белешмәәдәбият белән системалы эшләү.<br>5. Аудио-видео белән эш итә | 1. Уку мәсьәләсен куя белү.<br>2. Танып белү активлыгын үстерү.<br>3. Яңа теманы аңлауга мотив тудыру.<br>4. Төшенчә, термин, кагыйдә, закончалыкларны аңлап кабул итү күнекмәсен камилләштерү.<br>5. Логик алымнардан чагыштыру, анализ, гомумиләштерү, нәтиҗә ясау күнекмәләрен камилләштерү.<br>6. Грамматик анализ төрләрен үзләштерү: | 1. Телдән сөйләм:<br>• кагыйдәләрне аңлап эзлекле сөйли белү күнекмәсе;<br>• сорауны формалаштыра белү һәм тулы җавап бирә белү күнекмәсе.<br>2. Язма сөйләм:<br>• күчереп язу;<br>• сүзлек диктанты — 18-25 сүз;<br>• контроль диктант — уку елы башында - 60 - 65 сүз,<br>• уку елы ахырында – 65-70 сүз<br>• гади план буенча изложение язу: |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | белү. | • мөстәкыйль сүз төркемнәренә морфологик анализ.<br>7. Тикшеренү ысуллары:<br>• модельләштерү;<br>• охшатып эшләү. | -уку елы башында —140 - 160 сүзле текст (язманың күләме — 85 - 95 сүз);<br>-уку елы ахырында — 160- 190 сүзле текст (язманың күләме — 95 - 105 сүз);<br>-фикер йөртү элементлары кертеп, гади план төзеп сочинение язу |

## Гомумбелем күнекмәләрен бәяләүнең критерийлары һәм нормалары

**Язма эшләрнең күләме һәм аларны бәяләү:**

Сүзлек диктанты –18-25

**Сүзлек диктантын бәяләү**

1. Пөхтә язылган, хатасы булмаган эшкә “5” ле куела.
2. Бер орфографик хаталы эшкә “4” ле куела.
3. Өч орфографик хаталы эшкә “3” ле куела.
4. Биш орфографик хаталы эшкә “2” ле куела.

Контроль диктант- ел башында 55-65 сүз, ел ахырында 65-70 сүз

**Контроль диктантны бәяләү:**

1. Эш пөхтә башкарылса, хатасы булмаган эшкә “5” ле куела. (Бер – орфографик, ике пунктуацион хата булырга мөмкин.)
2. Ике орфографик, ике пунктуацион яки бер орфографик, дүрт пунктуацион хаталы эшкә “4” куела.
3. Дүрт орфографик, дүрт пунктуацион яки өч орфографик, алты пунктуацион хаталы эшкә “3” куела.
4. Алты орфографик, биш пунктуацион яки биш орфографик, сигез пунктуацион хаталы эшкә “2” куела.

Изложение текстының күләме

ел башында 140-160 сүз (85-95 –язма күләме)

ел ахырында 160-190 сүз (95-105- язма күләме)

**Изложениене бәяләү**

1. Тема тулысынча ачылган, фактик һәм техник хаталары булмаган, стиль бердәмлеге сакланган эшкә «5» ле куела. (Бер орфографик, ике пунктуацион яки ике грамматик хатасы булырга мөмкин.)
2. Текстның эчтәлеге темага нигездә туры килсә, фикерне белдерүдә зур булмаган ялгышлыклар җибәрелсә, бер-ике фактик, бер-ике техник хатасы булса, ике орфографик, ике-өч пунктуацион, бер грамматик хатасы булган эшкә «4» ле куела.
3. Язмада эчтәлек эзлекле бирелмәсә, стиль бердәмлеге сакланмаса, өч фактик, ике-өч техник хатасы булса, өч орфографик, дүрт пунктуацион, ике грамматик хатасы булган эшкә «3» ле куела.

4. Эзлеклелек, стиль бердәмлеге сакланмаса, язма эш планга туры килмәсә, фактик һәм техник хаталары күп булса, орфографик хаталарның саны дүрттән, пунктуацион хаталарның саны биштән, грамматик хаталар саны өчтән артса, «2» ле куела. Сочинениенең күләме һәм аны бәяләү

Иҗади эшнең бер төре буларак, сочинение — укучының язма рәвештә үти торган эше. Ул бәйләнешле сөйләм үстерү күнекмәләре булдыруда зур әһәмияткә ия. Әдәби (хикәяләү, очерк, истәлек, хат, рецензия һ. б.), әдәби- иҗади, өйрәтү характерындагы, ирекле, рәсемнәр нигезендә үткәрелә торган һәм контроль сочинениеләр була.

Соинениенең күләме- 1-2 бит

**Сочинениене бәяләү**

1. Язманың эчтәлеге темага тулысынча туры килсә, фактик ялгышлары булмаса, бай телдә, образлы итеп язылса, стиль бердәмлеге сакланса, «5» ле куела. (Бер орфографик яисә ике пунктуацион (грамматик) хата булырга мөмкин.)
2. Язманың эчтәлеге нигездә темага туры килсә, хикәяләүдә зур булмаган ялгышлыклар күзәтелсә, бер-ике фактик хата җибәрелсә, теле бай, стиль ягы камил булып, ике орфографик, өч пунктуацион (грамматик) яисә бер-ике сөйләм ялгышы булса, «4» ле куела.
3. Эчтәлекне бирүдә җитди ялгышлар, аерым фактик төгәлсезлекләр булса, хикәяләүдә эзлеклелек югалса, сүзлек байлыгы ярлы булса, стиль бердәмлеге дөрес сакланмаган җөмләләр очраса, өч орфографик, дүрт пунктуацион (грамматик) яисә өч-дүрт сөйләм хатасы булса, «3» ле куела.
4. Язма темага туры килмичә, фактик төгәлсезлекләр күп булып, план нигезендэ язылмаса, сүзлек байлыгы бик ярлы булса, текст кыска һәм бер типтагы җөмләләрдән торып, сүзләр дөрес кулланылмаса, стиль бердәмлеге сакланмаса, биш орфографик, сигез пунктуацион (грамматик) яисә дүрт—алты сөйләм хатасы булса, «2» ле куела.

**Укыту – методик комплекты.**

1. ”Рус телендә урта(тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә татар телен һәм әдәбиятын укыту программасы” 1-11 нче сыйныфлар. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән, Казан, “Мәгариф” нәшрияты, 2011 нче ел
2. Н.В.Максимов, М.З.Хәмидуллина. ”Татар теле , 6нчы сыйныф” ,Рус телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы , Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2015 нче ел
3. “Урта мәктәптә татар теле укыту” Н.В.Максимов. Казан “Мәгариф” нәшрияты, 2004 нче ел (Укытучылар өчен методик кулланма).
4. “Диктантлар җыентыгы”(5-11 нче сыйныфлар өчен) З.Н.Хәбибуллина, Г.Ш.Нәбиуллина. Казан”Мәгариф” нәшрияты, 2003 нче ел.
5 . “Контроль диктантлар һәм изложениеләр”.. Н.Гыймадиева, Р.Баһавиева,Казан,”Яңалиф”нәшрият йорты,2004.
6. “Татар теленнән диктантлар һәм изложениеләр җыентыгы”(5-11 нче сыйныфлар өчен) Н.В.Максимов, С.М.Трофимова. Казан”Мәгариф” нәшрияты, 2005 нче ел

**Өйрәнелә торган материалның сәгатьләргә бүленеше.**

| № | *Бүлекләр, темалар* | **Сәгатьләр саны** | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | **Барлыгы** | **Теоритик материал** | **Кабатлау** | **Бәйләнешле сөйләм үстерү** |
| 1 | 5нче сыйныфта үткәннәрне кабатлау | 6 | | 4 | 2 |
| 2 | Морфология турында гомуми мәгълүмат | 1 | 1 | | |
| 3 | Исем | 26 | 18 | 2 | 6 |
| 4 | Сыйфат | 11 | **7** | 1 | 3 |
| 5 | Сан | 14 | 11 | 1 | 2 |
| 6 | Рәвеш | 17 | 10 | 1 | 7 |
| 7 | Алмашлык | 17 | 16 | 1 | 8 |
| 8 | 6нчы сыйныфта үткәннәрне кабатлау | 4 | | 4 | |
| | Барысы: | 105сәг. | 63 | 14 | 28 |
| 9 | Бәйләнешле сөйләм телен үстерү | 28 | | | |

| **1ч** | **2ч** | **3ч** | **4ч** | **еллык** |
|---|---|---|---|---|
| 27 | 21 | 30 | 27 | 105 |

**Практик өлеше**

| **Исеме** | **1ч** | **2ч** | **3ч** | **4ч** | **еллык** |
|---|---|---|---|---|---|
| **Диктант** | **2** | **1** | **3** | **2** | **8** |
| **Изложение** | **-** | **2** | **2** | **1** | **5** |
| **Сочинение** | **2** | **1** | **1** | | **4** |
| **Б.С.Ү** | **2** | **2** | **2** | **1** | **7** |
| **Барысы** | **6** | **6** | **8** | **4** | **24** |

**6 нчы сыйныф өчен татар теленнән календарь - тематик план**

| № | Дәрес темасы | Сәгсаны | Көтелгән нәтиҗәләр | Контроль төре | Уку-укыту эшчәнлегенең төрләре | Үтәлү вакыты | | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | План | Факт | |
| 1 | Бсү.”Туган телем – иркә гөлем” | 1 | **1 чирек** | Хикәя язу | Туган тел турында үз фикереңне әйтә белү | 2.09 | | |
| 2 | Авазлар һәм хәрефләр.Сузык һәм тартык авазлар. Сингармонизм | 1 | Аваз-хәреф анализы. Сүзләргә басым кую тәртибе. | | Укытучы сүзе, дәреслек, танып белү активлыгын үстерү | 4.09 | | |
| 3 | Сүзнең мәгъ нәле кисәкләре, тамыр, кушымча, нигез | 1 | Сүзләрне тамыр һәм кушымчаларга аеру, кушымча төрләрен белү | | Җөмләләр язу, логик фикер йөртү, чагыштыру, анализ, гомумиләштерү, нәтиҗә ясау | 5.09 | | |
| 4 | Җөмлә кисәкләре | 1 | Ия, хәбәр, тәмамлык, аергыч, хәлне таба белү; гади һәм кушма хәбәрне аеру | | Логик фикер йөртү, чагыштыру, анализ, гомумиләштерү, нәтиҗә ясау | 9.09 | | |
| 5 | Кушымча төрләре . | 1 | Мөнәсәбәт белдерүче кушымчаларны билгели белү | | | 11.09 | | |
| 6 | 5 нче сыйныфта үткәннәрне кабатлауга кереш контроль диктант “Казан” (Контроль диктантлар һәм изложениеләр.2004. Н.Гыймадиева, Р.Баһавиева,32 б) | 1 | Дөрес язу күнекмәләре булдыру | .Диктант | Кереш диктант | 12.09 | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 7 | Сүз төркемнәре турында төшенчә. | 1 | Мәгънәләре һәм грамматик билгеләре буенча бер төркемгә берләштерелә торган сүзләрне сүз төркемнәре дип атау. Телдә барлыгы 12 сүз төркеме булу. Аларның мөстәкыйль (исем, сыйфат, рәвеш, сан, алмашлык, фигыль, аваз ияртемнәре), бәйләгеч (бәйлек, теркәгеч), модаль (хәбәрлек сүз, ымлык, кисәкчә) сүз төркемнәренә бүленүе. | | Логик фикер йөртү, чагыштыру, анализ, гомумиләштерү, нәтиҗә ясау | 16.09 | | |
| 8 | Исем | 1 | Исем − предметны һәм затларны белдерүче сүз төркеме. Исем сүз төркеменең сораулары | | | 18.09 | | |
| 9 | Ялгызлык һәм уртаклык исемнәр. | 1 | . Бер төрдән булган предметлар, затлар өчен уртак исемнәрнең уртаклык исем, бер төрдән булган предмет һәм затларның берсенә генә бирелгән исемнең ялгызлык исем булуы. Ялгызлык, уртаклык исемнәр. | Сүзлек диктанты. (Ялгызлык, уртаклык исемнәр). | Логик фикер йөртү, чагыштыру, анализ, гомумиләштерү, нәтиҗә ясау | 19.09 | | |
| 10 | БСҮ.Сочинение “Көз килде” | 1 | Телдән сөйләм һәм язма сөйләм осталыгы, күнекмәләрен булдыру | Сочинение "Көз килде”. | Сөйләм төзү | 23.09 | | |
| 11 | Исем ясагыч кушымчалар. | 1 | Исем ясагыч кушымчаларның, тамырга яки нигезгә ялганып, яңа мәгънәле лексик берәмлек барлыкка китерүе. Бу сүзләрнең ясалма сүзләр дип йөртелүе. | Тест | Дәреслек, сүзлек белән эш итә белү, танып белү активлыгын үстерү | 25.09 | | |
| 12 | Исемнәрнең ясалыш төрләре | 1 | Ясалышлары ягыннан исемнәрнең төрле булуы. Аларның ясагыч кушымча ялганып ясалуы. Кушма, парлы, тезмә, кыскартылма ясалулары. | | Дәреслек, сүзлек белән эш итә белү, танып белү активлыгын үстерү | 26.09 | | |
| 13 | Исемнәрнең ясалыш төрләре | 1 | Ясалышлары ягыннан исемнәрнең төрле булуы. Аларның ясагыч кушымча ялганып ясалуы. Кушма, парлы, тезмә, кыскартылма ясалулары. | | Дәреслек, сүзлек белән эш итә белү, танып белү активлыгын үстерү | 30.09 | | |
| 14 | Бсү “ Исемең матур, кемнәр куйган” | 1 | Сүзлек белән эш | Хикәя язу | Сүзлек белән эшләү | 2.10 | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 15 | Бсү Сочинение ”Минем яраткан укытучым” | 1 | Телдән сөйләм һәм язма сөйләм осталыгы, күнекмәләре булдыру. | Сочинение | Сочинение язу | 3..10 | | |
| 16 | Исемнәрнең берлек-күплек төре. | 1 | Исемнәрнең күплек төренә *-нар, -нәр* кушымчалары ялгану. | | Дәреслек, сүзлек белән эш итә белү, танып белү активлыгын үстерү | 7.10 | | |
| 17 | Исемнәрнең килеш белән төрләнеше. | 1 | Исемнәрнең 6 килеше булуы. Баш килешнең кушымчасыз, калган килешләрнең кыек килешләр дип аталуы. Килеш кушымчалары. Баш килештәге исемнәрнең төрле җөмлә кисәге була алуы. | | Килешләрне өйрәнү, кагыйдәләр белән эш, күнегүләр эшләү | 9.10 | | |
| 18 | Яңгырау һәм саңгырау тартыкка беткән исемнәрнең килеш белән төрләнеше | 1 | Килеш кушымчаларын һәм ялгану очракларын дөрес билгеләү | | | 10.10 | | |
| 19 | Борын авзларына беткән исемнәрнең килеш белән төрләнеше | 1 | Килеш кушымчаларын һәм ялгану очракларын дөрес билгеләү | Аңлатмалы диктант | | 14.10 | | |
| 20 | Исемнәрнең юнәлеш, чыгыш һәм урын-вакыт килеше кушымчалары мәгнәсе | 1 | Рус телендәге предлогларны һәм килнш кушымчаларын чагыштырып нәтиҗәясый белү | | | 16.10 | | |
| 21 | Исемнәрнең тартым белән төрләнеше. | 1 | Исемнәрнең предмет, затның башка бер предметка, затка кара ганлыгын тартым кушымчалары аша белдерүе. Тартым кушымча-ларының предмет яки затның сөйләүчегә (*мин, без*), тыңлаучы-га (*син, сез*) сөйләмдә катнаш-маган затка яки предметка (*ул, алар*) караганлыгын белдерүе. | Иҗади диктант | Дәреслек, сүзлек белән эш итә белү, танып белү активлыгын үстерү | 17.10 | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 22 | Тартымлы исемнәрнең килеш белән төрләнеше. | 1 | Тартымлы исемнәрнең килеш белән төрләнешендәге үзенчәлекләр. | Диктант – 7 мин. | Дәреслек, сүзлек белән эш итә белү, танып белү активлыгын үстерү | 21.10 | | |
| 23 | Диктант язу "Әдәпле бала нинди була?" | 1 | Дөрес язу күнекмәләре булдыру | Диктант | Үз-үзеңә контроль ясау | 23.10 | | |
| 24 | Тартымлы исемнәрнең килеш белән төрләнеше. | 1 | Тартымлы исемнәрнең килеш белән төрләнешендәге үзенчәлекләр. | | Дәреслек, сүзлек белән эш итә белү, танып белү активлыгын үстерү | 24.10 | | |
| 25 | Мәкалә язу. | 1 | | Мәкалә язу | | 28.10 | | |
| 26 | Алынма исемнәрнең төрләнеш һәм әйтелеш үзенчәлекләре. | 1 | Алынма исемнәрдәге –ск кушым-часы татар телендә –ски формасын алып, сүзләргә калын кушымча ялгану. (й) авазына беткән алынмаларга тартым кушымчасы ялганганда, й хәрефенең е хәрефе белән алышынуы. Ь хәрефенә беткән исемнәргә тартым кушымчасының нечкә төре ялгануы. | | Кагыйдәләр белән эш, күнегүләр эшләү | 30.10 | | |
| 27 | Исемнәрнең җөмләдә кулланылышы. | 1 | Баш килештәге исемнең ия, хәбәр, тәмамлык, аергыч, хәл булып килә алуы. Җөмләдә и. килешендәге исем исем-аергыч, т.килешендәге исем-тәмамлык, ю.к. , ч.к., у-в. килешләрендәге исемнәр-хәл булуы. | Сүзлек диктанты. | Дәреслек, сүзлек белән эш итә белү, танып белү активлыгын үстерү | 31.10 | | |
| | | | **2 чирек** | | | | | |
| 28 | Исемнәрнең җөмләдә кулланылышы | 1 | | | | 11.11 | | |
| *29* | Бсү. Контроль изложение. | 1 | Эчтәлекне аңлау, гади план нигезендә төгәл итеп язып бирү. | Изложение | Үз-үзеңә контроль ясау | 13.11 | | |
| 30 | Бсү Хат язу | 1 | Үткәннәрне ныгытуга күнегүләр эшләү | | Күнегүләр эшләү | 14.11 | | |
| 31 | Кабатлау.Килеш кушымчаларының мәгнәләре | 1 | Килеш кушымчаларын белү, тартым белән төрләндерү | Тест | Эзләнү таләп итә торган мәсьәләләрне чишү юлларын үзләштерү. | 18.11 | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 32 | Исемнәрне кабатлау | 1 | | Тест | | 20.11 | | |
| 33 | Исемгә морфологик анализ | 1 | Исемнәрне морфологик яктан тикшерү. | | | 21.11 | | |
| 34 | Исемгә морфологик анализ | 1 | Исемнәрне морфологик яктан тикшерү | | | 25.11 | | |
| 35 | Сыйфат турында төшенчә. | 1 | Сыйфатны предметның билгесен белдереп, *нинди? кайсы? Кайда-гы?* сорауларына җавап бирүе. Аның исемне ачыклап килүе. Сыйфат ачыклаган исемнең сый-фатланмыш булуы. Сыйфатның җөмләдә күбрәк аергыч һәм хәбәр булып килүе. | Сүзлек диктанты. | Логик фикер йөртү, чагыштыру, анализ, гомумиләштерү, нәтиҗә ясау | 27.11 | | |
| 36 | Асыл һәм нисби сыйфатлар. | 1 | Асыл һәм нисби сыйфатларның төп билгеләре. | | кагыйдәләр белән эш, күнегүләр эшләү | 28.11 | | |
| 37 | Сыйфатларның ясалышы . | 1 | Сыйфатларның ясалышы буенча төрләре: тамыр, кушымча ялгау юлы белән ясалган сыйфатлар, кушма, парлы һәм тезмә сыйфат-лар. Ясалма сыйфатларның күб-рәк исем һәм фигыльләргә мах-сус кушымчалары ялганып яса-луы. Сыйфат ясагыч кушымча-лар: *-лы*; *-ле, -сыз, -сез, -гы, -ге, -кы, -ке*; *-чан, -чән, -ык, -ек, -к, -ынкы, -енке, -ма, -мә, -гыч, -ген, -лык,-лек*. Гарәп-фарсы, рус һәм башка телләрдән алынган сүзләрдән ясалган сыйфатлар. | Хәтер диктанты, 56 бит, 90нчы күнегү | Дәреслек, сүзлек белән эш итә белү, танып белү активлыгын үстерү | 2.12 | | |
| 38 | Бсү Картина буенча сочинение язу “ Урамда кыш” | 1 | Тартым һәм килеш белән төрләнгән ялгызлык исемнәрен кулланып язу. | Сочинение | Үз-үзеңә контроль ясау | 4.12 | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 39 | Сыйфат дәрәҗәләре. | 1 | Татар телендә дүрт сыйфат дәрә җәсе булуы. Гади дәрәҗәдәге сыйфатлар предметның гадәти (төп) билгесен белдерүе. Чагыш-тыру дәрәҗәсендәге сыйфатлар- ның бер предметтагы билгенең башка предметтагы билге белән чагыштырганда, я бераз артыг-рак, я азрак булуын күрсәтүе (*-рак, -рәк* кушымчалары ялга-нып ясала). Артыклык дәрәҗәсенең сыйфатның бер иҗегенә җайлаш тырылган көчәйткеч кисәкчәләр ярдәмендә; *иң, утә, җете, дөм* һәм башка кисәкчәләр белән; бер үк сыйфатны кабатлау аша яса-луы. Сыйфатның кимлек дәрәҗә сенең *-су, -ча, -сыл, -сел, -мса, -гылт, -гелт, -кылтым, -келтем, -елҗем* кебек кушымчалар ярдә-мендә ясалуы. | | Логик фикер йөртү, чагыштыру, анализ, гомумиләштерү, нәтиҗә ясау | 5.12 | | |
| 40 | Сыйфатларның җөмләдә кулланылышы. | 1 | Җөмләдә сыйфатларның, гадәттә, аергыч, хәбәр, хәл булып килүе. | Диктант – 10 мин. | Логик фикер йөртү, чагыштыру, анализ, гомумиләштерү, нәтиҗә ясау | 9.12 | | |
| 41 | Бсү “Минем сыйныфташым” | 1 | Сыйфатларны кулланып, сыйныфташың турында сөйли белү | Хикәя язу | | 11.12 | | |
| 42 | Контроль диктант ( “.Беренче кар”) | 1 | Грамоталылык дәрәҗәсен тикшерү, белемнәрне тикшерү | Диктант | | 12.12 | | |
| 43 | Сыйфатларның исемләшүе. | 1 | Сыйфатланмыштан башка килгән исемнәрнең килеш һәм тартым белән төрләнүләре, берлек Һәм күплек санда килүләре. Бу күренешнең сыйфатларның исемләшүе дип аталуы. | | Кагыйдәләр белән эш, күнегүләр эшләү | 16.12 | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 44 | Сыйфатларны кабатлау | 1 | Сыйфатларга морфологик анализ ясый белү. Тема буенча үтелгәннәрне кабатлау. | Тест | Логик фикер йөртү, чагыштыру, анализ, гомумиләштерү, нәтиҗә ясау, эзләнү таләп итә торган мәсьәләләрне чишү юлларын үзләштерү. | 18.12 | | |
| 45 | Сыйфатларга морфологик анализ ясау. | 1 | Сыйфатларга морфологик анализ ясарга өйрәнү | | чагыштыру, анализ, гомумиләштерү, нәтиҗә ясау, | 19.12 | | |
| 46 | Изложение язу. | 1 | Эчтәлекне аңлау, гади план нигезендә төгәл итеп язып бирү. | Изложение | Үз-үзеңә контроль ясау | 23.12 | | |
| 47 | Сан турында төшенчә. | 1 | Предметның санын, исәбен белдереп, *ничә? күпме? никадәр? ничәнче? ничәләп? ничәү? ничәшәр?* сорауларының берсенә җавап булган сүз төркеменең сан дип аталуы. Җөмләдә санның күбрәк исемне ачыклап килүе, аергыч булуы. Сан белән ачыкланган сүзнең саналмыш булуы. Санның күбрәк цифрлар белән язып күрсәтелүе. Гарәп һәм рим цифрлары һәм аларны куллану. | | Логик фикер йөртү, чагыштыру, анализ, гомумиләштерү, нәтиҗә ясау | 25.12 | | |
| 48 | Ясалышы ягыннан сан төрләре. | 1 | Ясалышлары буенча саннарның тамыр, кушма, парлы, тезмә төрләре булу, аларның дөрес язылышлары. | | Дәреслек, сүзлек белән эш итә белү, танып белү активлыгын үстерү | 26.12 | | |
| | | | **3 чирек** | | | | | |
| 49 | Саннарның исемләшүе | 1 | | | | | | |
| 50 | Гарәп һәм рим цифрларының язылышы. | 1 | Гарәп һәм рим цифрларының язылышын өйрәнү. | Сүзлек диктанты | Күчереп язу, | | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 51 | Сан төркемчәләре. Микъдар саны. | 1 | Белдергән мәгънә төсмерләренә һәм формаларына карап, саннарның биш (төп, тәртип, бүлем, чама, җыю) төркемгә бүленүе. Төп саннарның предметларның төгәл исәбен белдерүе һәм *ничә? күпме? никадәр?* сорауларына җавап булуы. Өлеш саннарының да шушы төркемгә керүләре. | Диктант – 10 мин. | Логик фикер йөртү, чагыштыру, анализ, гомумиләштерү, нәтиҗә ясау | | | |
| 52 | Тәртип саннары. Аларның мәгънәсе һәм кулланылышы. | 1 | Тәртип санының предметларның саналу яки урнашу тәртибен белдереп, *ничәнче?* соравына җавап булуы. Төп санга *-нчы*, *-нче*, *-ынчы*, *-енче* кушымчалары кушылып ясалуы. | | Күчереп язу, саналмышын табу, үзгәртү эше | | | |
| 53 | Бүлем саннары. Аларның мәгънәсе һәм кулланылышы. | 1 | Бүлем санының предметны тигез өлешләргә бүлүен белдереп, *ничәшәр? күпмешәр?* сорауларына җавап бирүе. Төп санга *-ар, -әр, -шар, -шәр* кушымчалары ялганып ясалуы. | Хикәя язу | Дәреслек, сүзлек белән эш итә белү, танып белү активлыгын үстерү | | | |
| 54 | Чама саннары. Аларның мәгънәсе һәм кулланылышы. | 1 | Чама санының предмет санын якынча белдерүе, *никадәр? ничәләп?* сорауларына җавап бирүе. Төп санга *-лап, -ләп, -ларча, -ләрчә, -нарча, -нәрчә* кушымчалары ялгап ясалуы. | Тест | Чама саннарын табу, саннарны сүз белән язу, сорауларга җавап бирү | | | |
| 55 | Бсү “Сабан туенда” | 1 | Саннарны кулланып сабантуй турында сөйли белү | Хикәя язу | | | | |
| 56 | Җыю саннары. Аларның мәгънәсе һәм кулланылышы. | 1 | Җыю санының бер төрдәге предметларның бергә туплану исәбен белдерүе, *ничәү? күпме?* сорауларына җавап бирүе. Төп санга *–ау, -әү* кушымчалары ялгап ясалуы. | | Сәнгатьле уку, җыю саннарына сору кую, дәреслек, сүзлек белән эш итә белү | | | |
| 57 | Изложение | 1 | Катлаулы план төзү, шул нигездә фикерне эзлекле язу. | Изложение | План төзү, фикерләрне язу | | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 58 | Саннарнын җөмләдә кулланылышы. Акт язу. | 1 | Эш кәгазьләреннән акт яза белү. Саналмышы белән килгән сан-нарның җөмләдә күбрәк аергыч булулары, төрләнмәве. Саналмы-шыннан башка килгән саннар-ның, исемнәр кебек, килеш һәм тартым белән төрләнүе, җөмләнең төрле кисәкләре булып килүләре. Математик гамәлләрдә кулланыла торган саннарның санал-мышсыз килеп төрләнә алуы һәм җөмләнең төрле кисәге булуы. | Акт язу. | Логик фикер йөртү, чагыштыру, анализ, гомумиләштерү, нәтиҗә ясау, эзләнү таләп итә торган мәсьәләләрне чишү юлларын үзләштерү. | | | |
| 59 | Саннарны гомумиләштереп кабатлау. | 1 | Саннарга морфологик анализ ясый белү. | Тест | Эзләнү таләп итә торган мәсьәләләрне чишү юлларын үзләштерү. | | | |
| 60 | Саннарга морфологик анализ | 1 | | | | | | |
| 61 | Аңлатмалы диктант | 1 | Грамоталылык дәрәҗәсен тикшерү. | Диктант | Саннарны танып-белү, төркемчәләрен билгели белү | | | |
| 62 | Бсү. Контроль сочинение | 1 | | | | | | |
| 63 | Рәвеш турында төшенчә. Рәвешләрнең җөмләдә кулланылышы. | 1 | Җөмләдә эш яки хәлнең билгесен белдереп, *ничек? кая? кайда? кайдан? күпме? никадәр?* кебек сорауларның берсенә җавап бирә торган сүз төркеменең рәвеш дип аталуы. Рәвешнең җөмләдә күб-рәк фигыльне, сирәгрәк сыйфат-ны һәм рәвешне ачыклап килүе, хәл кисәк булуы. Рәвешнең төр-ләнми торган сүз төркеме булуы. | | Логик фикер йөртү, чагыштыру, анализ, гомумиләштерү, нәтиҗә ясау, тәрҗемә итү | | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 64 | Рәвешләрнең ясалышы, дөрес язылышы. | 1 | Төзелеше ягыннан рәвешләрнең 5 төргә: тамыр, кушымчалар ялгау юлы белән ясалган, кушма, парлы, тезмә рәвешләргә бүле-нүе. Кушма рәвешләрнең кушы-лып, парлы рәвешләрнең сызык-ча аша, тезмә рәвешләрнең соста выndагы сүзләрнең аерым язылуы. | Тест | Мәгънәле кисәкләргә бүлү, сүзлек белән эш итә белү, танып белү активлыгын үстерү | | | |
| 65 | Рәвеш дәрәҗәләре. | 1 | Кайбер рәвешләрнең, сыйфатлар кебек үк, чагыштыру, артыклык дәрәҗәсендә килүләре. | | Логик фикер йөртү, чагыштыру, анализ, гомумиләштерү, нәтиҗә ясау | | | |
| 66 | Рәвеш төркемчәләре. Саф рәвешләр. | 1 | Мәгънәләре ягыннан рәвешләр-нең 6 төркемчәгә: саф, охшату-чагыштыру, күләм-чама, вакыт, урын һәм сәбәп-максат рәвешләр гә бүленүе. Саф рәвешләрнең эш-нең сыйфатын белдерүләре, *ничек? ни рәвешле?* сорауларына җавап булулары. | | Дәреслек, сүзлек белән эш итә белү, танып белү активлыгын үстерү | | | |
| 67 | Күләм-чама рәвешләре | 1 | Күләм-чама рәвешләренең эш яки билгенең күләм-чамасын белдерүләре, *күпме? ничаклы? никадәр? нихәтле?* сорауларына җавап бирүләре. | | Логик фикер йөртү, чагыштыру, анализ, гомумиләштерү, нәтиҗә ясау | | | |
| 68 | Изложение язу(контроль) | 1 | Катлаулы план төзү, шул нигездә фикерне эзлекле язу. | Изложение | | | | |
| 69 | Охшату-чагыштыру рәвешләре | 1 | Охшату-чагыш-тыру рәвешләренең эшнең үтәлү ысулын белдерүләре, *ни төсле?* соравына җавап булулары. | | Логик фикер йөртү, чагыштыру, анализ, гомумиләштерү, нәтиҗә ясау | | | |
| 70 | Контроль диктант | 1 | Белемнәрне гомумиләштерү, тәртипкә салу | Диктант | | | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 71 | Вакыт рәвешләре | 1 | \Вакыт һәм урын рәвешләренең эшнең үтәлү уры-нын һәм вакытын белдерүләре, *кайчан?* (вакыт рәвеше), *кайда? кая? кайдан?* (урын рәвешләре) сорауларына җавап бирүләре. | | Логик фикер йөртү, чагыштыру, анализ, гомумиләштерү, нәтиҗә ясау | | | |
| 72 | Урын рәвешләре | 1 | Вакыт һәм урын рәвешләренең эшнең үтәлү уры-нын һәм вакытын белдерүләре, *кайчан?* (вакыт рәвеше), *кайда? кая? кайдан?* (урын рәвешләре) сорауларына җавап бирүләре. | Хәтер диктанты | Тәрҗемә итү, сүзтезмәләр төзү, урын рәвешләренең җөмләдәге функциясен билгеләү | | | |
| 73 | Сәбәп-максат рәвешләре | 1 | Сәбәп-максат рәвешләренең эшнең сәбәбен, максатын белде-рүләре, *ник? нишләп? нигә? нилектән?* сорауларына җавап бирүләре. | Тест | Логик фикер йөртү, чагыштыру, анализ, гомумиләштерү, нәтиҗә ясау | | | |
| 74 | Рәвешләргә морфологик һәм морфологик-синтаксик анализ | | | Анализ ясау | Сүзлек белән эш итә белү, танып белү активлыгын үстерү, рәвешләрнең синонимнарын, антонимнарын табу | | | |
| 75 | Бсү “Рәхмәт – иң олы сүз” | 1 | | Хикәя язу | Тема буенча үз фикерләреңне әйтә белү | | | |
| 76 | Рәвешләрне гомумиләштереп кабатлау. | 1 | Тема буенча үтелгәннәрне камил ләштерү күнегүләре. Рәвешләргә морфологик анализ ясый белү. | Тест | Эзләнү таләп итә торган мәсьәләләрне чишү юлларын үзләштерү. | | | |
| 77 | Контроль диктант (**“**Изге Биләр җирләре.”) | 1 | | Диктант | Үз-үзеңә контроль ясау | | | |
| 78 | Тәрҗемә итү күнегүләре | 1 | Үткәннәрне ныгытуга күнегүләр эшләү | | | | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | **4 чирек** | | | | | |
| 79 | Алмашлык турында төшенчә. | 1 | Үзләрен атамыйча гына зат яки предметларга, аларның билгесе яки санына һәм хәлләренә күрсә тә торган сүзнең төркеменең ал-машлык дип аталуы. Алмашлык ларның җөмләнең теләсә кайсы кисәге булып килә алуы. | Диктант – 10 мин. | Логик фикер йөртү, чагыштыру, анализ, гомумиләштерү, нәтиҗә ясау | | | |
| 80 | Алмашлыкларның ясалышы. | 1 | Ясалышлары буенча алмашлык-ларның тамыр, ясалма, кушма, парлы, тезмә булулары. Алмашлыкларның җөмләнең теләсә кайсы кисәге булып килә алуы. | | Дәреслек, сүзлек белән эш итә белү, танып белү активлыгын үстерү | | | |
| 81 | Бсү. “Безнең гаилә” | 1 | Телдән сөйләм һәм язма сөйләм осталыгы, күнекмәләре булдыру. | Хикәя язу | | | | |
| 82 | Алмашлык төркемчәләре | 1 | Мәгънәләре буенча алмашлык-ларның җиде төркемгә бүленүе: зат алмашлыклары, күрсәтү ал-машлыклары, билгеләү алмаш-лыклары, сорау алмашлыклары, юклык алмашлыклары, билге-сезлек алмашлыклары, тартым алмашлыклары. | | Логик фикер йөртү, чагыштыру, анализ, нәтиҗә ясау,сөйләшү оештыру, тәрҗемә эше | | | |
| 83 | Зат алмашлыклары. | 1 | I һәм II зат ал-машлыклары сөйләмдә катнаш- кан затларны белдерә, берлек һәм күплек санда киләләр, килеш бе-лән төрләнәләр, III зат алмашлык лары *ул, алар* сөйләмдә катнаш маган, әмма шулар турында сүз барган зат яки предметларны бел дерәләр, берлек яки күплек санда киләләр. Зат алмашлыкларының килешләр белән төрләнүе. | | Логик фикер йөртү, чагыштыру, анализ, нәтиҗә ясау,сөйләшү оештыру, тәрҗемә эше | | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 84 | Тартым алмашлыклары. | 1 | Предметның кайсы затка кара-вын белдергән алмашлыкларның тартым алмашлыклары дип ата-лулары. Алар кайбер алмашлык-ларга *-ныкы, -неке* кушымчалары ялганып ясала. | Тест | Күчереп язу, фикер алышу, нәтиҗә ясау, | | | |
| 85 | Күрсәтү алмашлыклары. | 1 | Күрсәтү алмашлыкларының затка, предметка һәм шулай ук предмет яки эш-хәл билгеләренә күрсәтүе. Күрсәтү алмашлыкларының килешләр белән төрләнүе. | | Дәреслек, сүзлек белән эш итә белү, танып белү активлыгын үстерү | | | |
| 86 | Күрсәтү алмашлыкларының тартым, килеш белән төрләнеше | 1 | Күрсәтү алмашлыкларының предметның билгесенә яки рәвешенә ишарә иткәндә килешләр белән төрләнмәве, җөмләдә аергыч яки хәл булып килүләре. Күрсәтү алмашлыклары тартым белән төрләнгәндә аларга 3 зат кушымчасы ялгану. | Тест | Логик фикер йөртү, чагыштыру, анализ, гомумиләштерү, нәтиҗә ясау | | | |
| 87 | Тәрҗемә итү күнекмәләре. | 1 | Тәрҗемә итү күнекмәләре үткәрү | | Сүзлек белән эшләү, тәрҗемә итү | | | |
| 88 | Бсү. Изложение | 1 | Текстны җәенкеләндереп, төрле дәрәҗәдәге сыйфатларны файдаланып язу. | Изложение . | Үз-үзеңә контроль ясау | | | |
| 89 | Сорау алмашлыклары. | 1 | Сорау алмашлыкларының сорау формасында зат яки предметлар га, аларның билгесе яки санна-рына һәм хәлләренә күрсәтүе. | Тест | Әңгәмә, логик фикер йөртү, чагыштыру, анализ, гомумиләштерү, нәтиҗә ясау | | | |
| 90 | Сорау алмашлыкларының тартым, килеш белән төрләнеше | 1 | | | | | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 91 | Билгеләү алмашлыклары. | 1 | Билгеләү алмашлыкларының гадәттә затларны предметларны гомумиләштереп белдерүләре. Аларның исемне ачыклап аергыч булып килгәндә төрләнмәүләре. Үзләре ачыклаган сүз урынына килгәндә килеш, тартым белән төрләнүе, берлектә һәм күплектә килүләре. | Тест | Дәреслек, сүзлек белән эш итә белү, танып белү активлыгын үстерү | | | |
| 92 | Билгеләү алмашлыкларының тартым, килеш белән төрләнеше | | Үз алмашлыгының өч затка да каравы һәм тартым, килеш белән төрләнүе, берлектә һәм күплектә килүе. | | | | | |
| 93 | Диалогик сөйләм үстерү | 1 | Телдән сөйләм һәм язма сөйләм осталыгы, күнекмәләре булдыру. | | Сөйләшү оештыру, сөйләм төзү | | | |
| 94 | Билгесезлек алмашлыклары. | 1 | Билгесезлек алмашлыкларының сорау алмашлыкларына *әллә* сүзе яки *-дыр, -дер, -тыр, -тер* кисәк чәләре кушылып ясалулары. | Сүзлек диктанты. | Дәреслек, сүзлек белән эш итә белү, танып белү активлыгын үстерү | | | |
| 95 | Юклык алмашлыклары. | 1 | Юклык алмашлыкларының пред-метны, билгене кире кагуны яки аларның булмавын белдерүләре. Аларның сорау алмашлыклары алдына *һич* яки *бер* сүзләрен кую юлы белән ясалулары. | Диктант – 7 мин. | Төшенчә, термин, кагыйдә, закончалыкларны аңлап кабул итү | | | |
| 96 | Алмашлыкларның җөмләдә кулланылышы. | 1 | Үзләре күрсәткән сүзләр җөмлә-нең кайсы кисәкләре булса, алмашлыкларның да шул ук кисәкләр булып килүе. Алмашлыкларга морфологик анализ ясый белү. | Расписка язу. | Логик фикер йөртү, чагыштыру, анализ, гомумиләштерү, нәтиҗә ясау, эзләнү таләп итә торган мәсьәләләрне чишү юлларын үзләштерү. | | | |
| 97 | Контроль диктант (**“**Игелеклелек.”) | 1 | Телдән сөйләм һәм язма сөйләм осталыгы, күнекмәләре булдыру. | Диктант | | | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 98 | Алмашлыкларның сөйләмдә дөрес кулланылышы | 1 | Үзләре күрсәткән сүзләр җөмлә-нең кайсы кисәкләре булса, алмашлыкларның да шул ук кисәкләр булып килүе. | | | | | |
| 99 | Алмашлыкларны кабатлау | 1 | Алмашлыкларга морфологик-синтаксик анализ ясый белү. Алмашлык темасы буенча өйрәнгәннәрне ныгыту. | Тест | Анализ, гомумиләштерү, нәтиҗә ясау, логик фикер йөртү, чагыштыру, | | | |
| 100 | Алмашлыкларга морфологик анализ | 1 | | | | | | |
| 101 | Арадаш аттестация. Контроль диктант (**“**Әнием куллары.”) | 1 | Грамоталылык дәрәҗәсен тикшерү. | Контроль диктант | Үз-үзеңә контроль ясау | | | |
| 102 | Кабатлау. Тамыр һәм кушымча | 1 | Уку елы дәвамында үтелгәннәрне кабатлау. | | Сүзләрне тамыр, кушымчаларга аера белү | | | |
| 103 | Мөстәкыйль сүз төркемнәрен кабатлау | 1 | Үткәннәрне ныгытуга күнегүләр эшләү | | Сүз төркемнәрен танып-белү | | | |
| 104 | Кабатлау. Морфологик анализ | 1 | Үткәннәрне ныгытуга күнегүләр эшләү | | Сүзләрне морфологик яктан тикшерә белү | | | |
| 105 | Уку елы дәвамында үтелгәннәрне кабатлау | 1 | Үткәннәрне ныгытуга күнегүләр эшләү | Тест | Эзләнү таләп итә торган мәсьәләләрне чишү юлларын үзләштерү. | | | |
| **Бөтенесе: 105 сәг.** | | | | | | | | |

## Кушымта

### Кереш контроль эш (диктант)

### Казан

Казан - Татарстанның  башкаласы. Очкыч шәһәр өстеннән бер әйләнеш ясап алды. Исәпсез-хисапсыз йортлары, биек-биек манаралары, завод морҗалары һәм яшел бакчалары белән бик зур бер шәһәр калкып чыкты. Шул арада Булат белән Зиннур  Казан Кремлен күздән үткәрделәр. Иң биек урынга салынган Кремль югарыдан караганда да шәһәрдән калкурак булып күренә.Ап-ак Спас башнясы, кызыл кирпечтән салынган Сөембикә манарасы, сарайлар, яшел бакчалар – барысы соры таш койма белән уратып алынган.

(Контроль диктантлар һәм изложениеләр.2004. Н.Гыймадиева, Р.Баһавиева, 32 б)

**Бирем.**
1-3 җөмләләрдә исемнәрнең килешләрен  билгеләргә.

### 1 чирек өчен контроль эш (диктант)

### Әдәпле бала нинди була?

Әдәплелек – башка кешеләр белән аралашу осталыгы. Кешеләр бер-берсенә ярдәм итәргә, бер-берсе өчен хезмәт итәргә тиешләр.

Төзүчеләр безнең өчен йортлар төзиләр. Табиблар кешеләрне дәвалыйлар. Кемнәрдер урманнар, ә кемнәрдер икмәк үстерәләр, матур киемнәр тегәләр. Кешеләр бер-берсенә игътибарлы булырга, яхшылык эшләргә тиешләр.

Трамвайда торып олы кешегә урын бирергә, очрашканда “Сау булыгыз” дип әйтергә, авыру кешенең хәлен белергә кирәк. Бу бер дә авыр түгел.

(Л.Васильева Гангнус буенча)

**Бирем.**
Тексттан исемнәрне табарга, килешләрен билгеләргә.

### 2 чирек өчен контроль эш (диктант)

### Беренче кар.

Иртән теләмичә генә торып утырдым. Өй эче дә бүген яктырак күренә. Ә ул сихри яктылык урамнан керә икән. Тәрәзәгә күз салсам, бөтен җир ап-ак. Кичәге пычрак, яңгырлы көннең эзе дә калмаган. Бер төн эчендә кар үзенекен эшләгән. Барлык шыксызлыкны каплаган да куйган!

Мәктәпкә барганда нинди күңелле икәнен белсәгез иде сез! Аяк астында кар җыр суза. Шаян кар бөртекләре керфекләргә куна. (60 сүз)

(“Сабантуй” газетасыннан)

**Бирем.**
1 вариант. а) **Шыксызлыкны** сүзенә морфологик анализ ясарга.б) Тексттан сыйфатларны сыйфатланмышлары белән бергә табып язарга.
2 вариант. а) **Яктылык** сүзенә морфологик анализ ясарга. б)Тексттан сыйфатларны табып, ясалышы ягыннан төрен күрсәтергә.

**3 чирек өчен контроль эш (диктант)**

**Изге Биләр җирләре.**

Үткәнен белмәгәннең киләчәге юк, дигән безнең бабайлар. Без дә Изге Биләр җирләренә барып, Изге Чишмә суыннан авыз итеп кайтырга булдык.

Гаҗәеп тылсымлы, серле икән ул Биләр җирләре. Аның туфрагына аяк басуга, җаның сафлана, чистара, борынгы тамырларыңа якыная баруыңны тоясың.

Бу борынгы җирләрнең йөзек кашы – аның Изге Чишмәсе. Гасырлар авазы булып бүген дә челтерәп агып ятучы әлеге чишмәгә кайлардан гына килмиләр. Чишмә суын иреннәргә тидергәндә, күңелеңнең иң нечкә кылы зыңлап куя. (70 сүз)

(Й.Шәраповадан)

**Бирем.**
1 вариант. а**)**Тексттан асыл сыйфатларны табып, асларына сызарга.. б) **Тылсымлы** сүзенә морфологик анализ ясарга.
2 вариант. а)Тексттан рәвешләрне табып, асларына сызарга. б) **Борынгы** сүзенә морфологик анализ ясарга.

**4 чирек өчен контроль эш (диктант)**

**Игелеклелек.**

Безнең татар халкы элек-электән игелекле булган, мохтаҗларга ярдәм итүдән тәм тапкан. Элек үк татар байлары ярлы балалары өчен мәктәп-мәдрәсәләр салдырган. Шулай итеп, бергәләп тотынып, милләтне саклап калганнар. Менә хәзер йөз еллардан соң да без изгелек турында сүз кузгаттык. Әйе, безнең белән янәшәдә авыр тормышта яшәүче, бик күпкә бәхетсезрәк кешеләр дә бар. Ә һәркемнең бәхетле буласы килә. Кемнедер бәхетле итү кулыңнан килә икән, нигә аны эшләмәскә?!.)

(Й. Шәраповадан)

**Бирем.**
1 вариант. а)**Элек** сүзенә морфологик анализ ясарга. б)Тексттан алмашлыкларны табып, асларына сызарга.
2 вариант. а)**Хәзер** сүзенә морфологик анализ ясарга. б)Тексттан алмашлыкларны табып, асларына сызарга.

**2015-2016 нчы уку елына 6 нчы сыйныфта *татар теленнән* (татар төркеме) арадаш аттестация үткәрү ( контроль диктант)**

**Әнием куллары.**

Мин икенче тапкыр туган йортымда...

Әнә ул әни. Картайган, бик картайган инде. Кайчандыр кош канатыдай ялтырап торган кара чәчләре сирәкләнгән. Аларга хәзер бәс кунган кебек. Йөзе дә җыерчыкланып калган.

Мин әниемнең  кулларын күзәтәм. Көчемнән килсә, мин шушы кулларга һәйкәл куяр идем. Әнинең йөзен дә, гәүдәсен дә сурәтләмәс идем мин. Тик менә шушы ярылып беткән кулларны гына сурәтләр идем. Һәйкәлгә караган һәрбер кеше бу кулларның Бөек Ана куллары икәнен таныр иде. (К.Шәфыйковадан)

**Бирем.**

1 вариант. а)Җөмләләрдәге сүзләрнең кайсы сүз төркеменә каравын  билгеләргә.б)Үзегез теләгән бер алмашлыкка морфологик-синтаксик анализ ясарга.

2 вариант. а)Җөмләләрдәге сүзләрнең кайсы сүз төркеменә каравын  билгеләргә.б)Үзегез теләгән бер рәвешкә морфологик-синтаксик анализ ясарга.